РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.04.2020ел Буа шәһәре 124/ИК-п номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының энергетика объектларын «Челтәр компаниясе» ААҖнең энергетика объектларын чагылдыру өлешендә территориаль планлаштыруга үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 июнендәге 257/ик-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Буа муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының 2019 елның 11 июнендәге 257/ик-п номерлы Башкарма комитеты карарына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендәге 3-27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын территориаль планлаштыру схемасын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын нигезләү материалларын эшләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү буенча чаралар планын, чараларны үтәү срокларын расларга. (1 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына муниципаль районны электр белән тәэмин итү картасын әзерләү һәм тулыландыру өлешендә үзгәрешләр кертү эшләрен финанслау «Челтәр компаниясе» ААҖ акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Буа муниципаль районының

рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru/ һәм «Знамя» газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Г. Гыйззәтовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р. Камартдинов